**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.01.2018 г.Казань **№ 1-од**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 22 декабрендәге 01-02/821 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 01-02/265 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«контроль чараларны гамәлгә ашыру.»;

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегендә:

5 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«5. Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең “белгечләр” категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештырылыш һәм күзәтчелекне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә органнарына хокукый консультация-методик ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты.».

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә күзәтчелек итүне үз карамагымда калдырам.

Министр Р.И. Заһидуллин